СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **N 6**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Иске Кырлай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12а йорты, Иске Кырлай МСҮ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 19 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12а йорты, Иске Кырлай МСҮ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 19 ноябренә 12 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Ахун Сабиров, Яшел, Үзәк, Совет мәйданы, Чишмәле урамы халкы

2 нче этап: Яшьләр, Хади Такташ урамы халкы.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2026 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Кырлай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭС һәлакәтен бетерүдә катнашканнардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук

махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Иске Кырлай авылы Советлар мәйданы урамы, Яшьләр урамы)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Иске Кырлай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына: ТР, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12А йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ